**КАЛИМУЛЛИНА ГАЛИМА ГИМАЗЕТДИНОВНА**



Родилась в 1928 году в Бондюжском районе ТАССР. Трудовой путь начала подростком в годы войны в колхозе. Работала в сельском хозяйстве до 1994 года.

Воспитала шестерых детей. Награждена медалями «За доблестный труд в Великой Отечественной войне 1941-1945 гг.», «Ветеран труда», «Материнская слава» I и II степеней.

## Ананың төп байлыгы

Аның сугыш белән өтелгән балачагы колхоз кырларында үтә. – Барыбызга да бердәй авыр иде, – дип исенә төшерә ветеран. – Ачлык, ялангачлык, туганнарыбызны һәм якыннарыбызны югалту ачысын кичердек. Минем абыем Шәех та яу кырында башын салды. Безне, бәдәннәре дә ныгымаган кызларны, бригадалап урман эшләренә җибәрәләр иде. Кыенлыклар безне чыныктырды, бер генә үкенечем калды – белем ала алмадым. Галимә апаның хезмәт биографиясе 1994 елга кадәр, лаеклы ялга чыккач та дәвам итә. Г.Кәлимуллина I һәм II дәрәҗә «Ана даны», «Хезмәт ветераны» медальләре белән бүләкләнгән. Галимә Гыймазетдиновна үзен бәхетле әни һәм дәү әни дип исәпли – аны алты баласы, ун оныгы кайгырта, җиде оныкчыгы әбиләрен чиксез ярата. – Без үскәндә йорт мәшәкатьләре һәрберебезгә тигез бүленгән иде, – дип сөйли кызы Зәмфирә, – әни тегермәндә эшләде, соң кайта иде. Әмма аннан ипи исе килеп торган тойгы безне бүгенге көнгә кадәр озата бара. 1986 елда авыру әтиебезне аямады, әни аны алты ел тәрбияләде. Без, биш кызы һәм бер улы, башыбызны иеп кадерле кешебезгә барысы өчен дә «Рәхмәт!» дибез. – Безнең әби аның төп байлыгы булган искиткеч балалар үстерде, – дип дәвам итә кияве Илдар, –

хәзер тулы хокук белән оныкларының һәм оныкчыкларының уңышларына шатлана. Галимә Гыймазетдиновна кунакларга җылы котлаулары һәм бүләкләре өчен рәхмәт әйтте. – Сезгә бары тик уңышлар, сәламәтлек һәм оптимизм юлдаш булсын, – диде ветеран, – минем 95 яшемдә очрашырга язсын!

*Менделеевск хәбәрләре, 2018 ел, март*








BEST

